**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре № 283-38 «20» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 15.06.2015ел № 369-53 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларын раслау турында» карары белән расланган», Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру Нормативларына үзгәрешләр кертү турында
(13.12.2018 №221-32, 23.05.2019 №265-36 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Җир кодексын үтәү максатыннан, «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 29.05.2019 ел, №116-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә урманнарны саклауны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел № 538-ФЗ Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар чыгарды**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 15.06.2015ел № 369-53 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларын раслау турында» карары белән расланган»,
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру Нормативларына (13.12.2018 №221-32, 23.05.2019 №265-36 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 бүлектә:

а) 4.2.1 пунктның дүртенче абзацында «бакчачылык (дача)» сүзләрен «бакча җирләре» сүзләренә алмаштырырга»;

б) 4.2.28 пунктның беренче абзацында «бакча-дача» сүзләрен «бакча» сүзенә алмаштырырга»;

в) 4.2. пунктының беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Аны торак бинадан торак булмаган бинага күчергәннән соң, торак биналарга керү мөмкинлеген тәэмин итүче биналардан файдалану мөмкинлеге төшереп калдырылырга тиеш.».

1.2. 4.7 бүлектә:

а) 4.7.2, 4.7.3 пуктларда «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 5.1 бүлектә:

а) 5.1.4 пунктның беренче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек берләшмәләре, дача хуҗалыклары» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләр, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнар тарафыннан булдырылган коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 5.2 бүлектә:

а) 38 таблицаның «җир кырыенынннан ераклык, ким дигәндә» графасында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре» сүзләрен «коммерциячел булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре» сүзләренә алмаштырырга.

б) 62 таблицаның «биналар һәм корылмалар, рекреация территорияләре һәм ял объектлары» графасында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләр, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнар тарафыннан булдырылган коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

1.51.5. 7.3 бүлектә:

а) 7.3.22 пунктта:

- икенче абзацта «(урман парклары)» сүзен төшереп калдырырга;

- өченче, дүртенче һәм бишенче абзацларда «(урман парклары)» сүзен төшереп калдырырга» ;

б) 7.3.23 пунктта «(урман паркларында)» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 7.3.27 пунктта «(урман парклары)» сүзен төшереп калдырырга

1.67.4 бүлектә:

а) 7.4.16 пунктта:

- беренче абзацта «бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «гражданнар тарафыннан бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләрен үз ихтыяҗлары өчен» сүзләренә алмаштырырга»;

- икенче абзацта «бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре» сүзләренә алмаштырырга.

1.7. Азнакай муниципаль районы төзелешен проектлаштыру Нормативларына №1 кушымтада «Федераль законннар» бүлегендә:

а) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 29.07.2017 ел № 217-ФЗ Федераль закон;».

1.8. Азнакай муниципаль районының төзелеш проектлаштыру Нормативларына 3 нче кушымтаның 4 нче таблицасында:

а) V бүлекнең «Сәүдә объектлары, шул исәптән: киосклар, павильоннар, кибетләр, сәүдә үзәкләре, сәүдә комплекслары» дигән 5 графада «бакчачылык һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләр, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнар тарафыннан булдырылган коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

1.9. Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру Нормативларына №9 кушымтаның 1, 2, 3, 4 таблицаларында «(урман парклары)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен Азнакай муниципаль районы Советының торак-коммуналь хуҗалыгы, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин